СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«УРМЫШЛИНСКОЕ СЕЛЬСКОЕ
ПОСЕЛЕНИЕ»
ЛЕНИНОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«УРМЫШЛЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

Урмышлы

2022 елның 17 мае №8

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Урмышлыавыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2017 елның 1 августындагы 18 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Урмышлыавыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны һәм контракт буенча башкарма комитет җитәкчесе вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан тапшырылган керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматларны Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Урмышлыавыл җирлеге» муниципаль берәмлеге рәсми сайтында «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә һәм массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгару өчен мәгълүмат бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

«Цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 31 июлендәге 259-ФЗ номерлы Федераль законга таянып, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 40 статьясындагы 7.4 өлешен, 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы «Коррупциягә каршы тору турында» Федераль законның 12.1 статьясының 4.3 өлешен, «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законның 8 статьясының 4 өлешен гамәлгә ашыру максатларында, Лениногорск шәһәре прокуратурасының 2022 елның 16 маендагы 02-08-03 номерлы протестын карап, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Урмышлы авыл җирлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Урмышлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2017 елның 1 августындагы 18 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Урмышлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны һәм контракт буенча башкарма комитет җитәкчесе вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан тапшырылган керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматларны

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Урмышлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге рәсми сайтында «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә һәм массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгару өчен мәгълүмат бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

3 пунктның «г» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«г) әгәр мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы вазыйфаи затның һәм аның хатынының (иренең) хисап чорына кадәрге соңгы өч ел эчендә гомуми кеременнән артып китсә, җир кишәрлеге, башка күчемсез милек объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр (оешмаларның устав (туплау) капиталларында катнашу өлеше, пайлары), цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта сатып алу буенча алыш-бирешләр (алыш-бирешләр башкарылган) башкарылган средстволар алу чыганаклары турында белешмәләр.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Урмышлы авылы, Үзәк урам, 4, Яңа Елховой авылы, Чишмәле урамы, Бохар авылы Авангард урамы,22 адресы буенча урнашкан махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Лениногорск муниципаль районы рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
«Урмышлыавыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге
башлыгы, Совет рәисе — А.Ф.Хәбибуллин